**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 160

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 ноябрь, 972 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 8 ноябрь, 972 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 27 ноябрь, 900 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының балалар, яшьләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен, аларны фәнни-техник, инновацион һәм җитештерү тармакларында үстерү максатларында матди-техник, икътисадый, мәгълүмати база булдыру юлы белән уңайлы шартлар тудыруга

юнәлдерелгән яшьләр инновацион иҗат үзәкләрен оештыру һәм үстерү белән бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_{к} + З_{о.к.о} + З_{д.к.о} + З_{р.м},$$

монда:

С – бирелә торган субсидия күләме;

$З_{к}$ – командировкаларга чыгымнар;

$З_{о.к.о}$ – җиһазларның төп (мәҗбүри) комплектын сатып алуга, шул исәптән китертүгә һәм кору-көйләү эшләренә чыгымнар;

$З_{д.к.о}$ – өстәмә җиһазлар сатып алуга чыгымнар;

$З_{р.м}$ – чыгым материаллары сатып алуга чыгымнар.»;

2.1 нче пунктның 2.1.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1.3. Субсидия бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның бересенә түбәндәге таләпләргә туры килү:

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиеш салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча, шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятенә иминиятләү кертемнәре буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән) кайтару буенча вакыты чыккан бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына башка вакыты чыккан бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, ябылу, банкротлык процессында булмау һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләре булмау;

теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган салым салуның ташламалы салым режимы бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре үткәргәндә мәгълүмат ачу һәм бирү күздә тотылмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналар) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган устав (җыелма) капиталларындагы чит ил юридик затлары катнашу өлеше барысы бергә 50 процenttан арткан чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә әлеге Тәртипнең 1.3 нче пунктында күрсәтелгән максатларга акча алмау.»;

3.3 нче пунктта «әлеге Тәртипнең 3.2 нче пунктында билгеләнгән...» сүзләреннән соң «дөрес булмавы» сүзләрен өстәргә;

4.1 нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эшмәкәрлек субъектының әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе

турында гариза бирүче имзалаган белешмә (ирекле формада);»;

4.3 нче пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Иҗат үзәге урнашкан күчемсез мөлкәт объектына (бинага) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә бинага ия булу хокукын һәм (яки) бинадан файдалану хокукын раслый торган документ.»;

5.16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.16. Субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Вәкаләтле орган конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүче белән субсидия бирү турында шартнамә төзи.

Субсидия бирү турында шартнамә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма буенча төзелә.

Субсидия бирү турында шартнамәдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, аннан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе, формалары һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кайтару очраклары, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы алуны тыю, Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә югары технологияле импорт җиһазлары, чимал һәм комплектлау җайланмалары сатып алганда (кайтартканда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, субсидия алучының әлеге Тәртип шартларын үтәү турындагы нигезләмәне үтәүгә тикшерүләр гамәлгә ашыруга субсидия алучының (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашкан җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерциячел оешмалардан тыш) ризалыгы күздә тотыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\160.doc